**Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен татар теленнән республика олимпиадасының муниципаль туры сораулары җаваплары 2017-2018 уку елы. 4 нче сыйныф**

**Үткәрү вакыты - 90 минут**
**максималь балл - 58**

## I. Тестлардан берәр дөрес җавапны билгеләгез.

1. Тартык авазларны белдерә торган хәрефләр саны дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (2 балл)
   а) 13;
   **ә) 24;**
   б) 28;
   в) 39.

2. Калын сузык авазлардан гына торган мәкальне билгеләгез. (2 балл)
   а) Сөйдергән дә – тел, биздергән дә – тел.
   ә) Күп сүзнең кыскасы яхшы.
   б) Кеше дуслыкта сынала.
   **в) Саескан сайраса да сандугач булмас.**

3. Хәреф белән аваз саны туры килгән сүзләрдән генә торган рәтне билгеләгез. (2 балл)
   а) егет, вәгъдә, фигыль;
   ә) нефть, сәгать, тәкъдим;
   **б) ашъяулык, ятьмә, меңъяфрак;**
   в) мөгаен, спектакль, пульс.

4. Мәсәлләрдә, экиятләрдә җәнлекләр һәм кошлар ничек язылганлыгы дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (2 балл)
   **а) баш хәрефтән;**
   ә) юл хәрефеннән;
   б) куштырнаклар эченә алынып;
   в) баш хәрефтән һәм куштырнаклар эченә алынып.

5. Татар телендә **В** хәрефенең язылышы дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (2 балл)
   а) сүз башында гына языла;
   ә) иҗек башында гына языла;
   **б) сүз һәм иҗек башында языла;**
   в) сүз һәм иҗек ахырында языла.

6. Башка телләрдән кергән сүзләрнең атамасы дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (2 балл)

а) яңа сүзләр;

**ә) алынма сүзләр;**

б) искергән сүзләр;

в) синонимнар.

7. Ясалма сүзләрдән генә торган рәтне билгеләгез. (2 балл)

**а) кульъяулык, көрәк, ата-ана;**

ә) агачлык, бозгыч, итәк;

б) бәрәңге, карбыз, тавык;

в) аккош, урман, аш-су.

8. Калын хәрефләр белән бирелгән исемнең килеше дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (2 балл)

*Татлы тел* ***еланны*** *да өненнән чыгарыр.* (Мәкаль)

а) баш килеш;

ә) иялек килеше;

**б) төшем килеше;**

в) чыгыш килеше.

9. Җөмләдәге фигыльнең заманы һәм зат-сан кушымчалары дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (2 балл)

*Татлы тел тимер капканы да ачар.* (Мәкаль)

а) хәзерге заман, III зат берлек санда;

ә) үткән заман, III зат күплек санда;

б) киләчәк заман, II зат берлек санда;

**в) киләчәк заман, III зат берлек санда.**

10. Җөмләдәге калын хәрефләр белән бирелгән фигыльнең үзенчәлекләре дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (2 балл)

*Исем кешене* ***бизәми****, кеше исемне бизи.* (Мәкаль)

а) хәзерге заман хикәя фигыль, барлыкта, III зат берлек санда;

**ә) хәзерге заман хикәя фигыль, юклыкта, III зат берлек санда;**

б) киләчәк заман хикәя фигыль, юклыкта, III зат берлек санда;

в) хәзерге заман хикәя фигыль, юклыкта, II зат берлек санда.

## II. Башыгызны эшләтегез.

Сузык авазга башланган һәм сузык авазга тәмамланган сүзләрдән генә торган “Ял көне” дип аталган текст төзеп языгыз. Барлыгы 10 җөмлә һәм алар җәенке булсын. (10 балл)

## III.Теоретик бирем.

Тамыр һәм ясалма сүзләр турында белгәннәрегезне языгыз. (10 балл)

## IV. Гамәли-иҗади бирем.

1. ***Балыкчылар*** сүзенә аваз-хәреф анализы ясагыз. (5 балл)
2. Аны сүз төзелеше ягыннан тикшерегез. (3 балл)
3. Балыкчы турында 12-15 җөмләдән торган бәйләнешле текст языгыз. (10 балл)

Текст язуга таләпләр:
- текст төзелеше ( башлам, төп өлеш, йомгаклау);
- җөмләләр дөрес, төзек булырга тиеш;
- язма телнең  бай, сурәтле булуына  игътибар итәргә;
- орфографик грамоталылыкка игътибарлы булырга.